| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.01.2024 с.Старое Дрожжаное № 36

«Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет даирәсе хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүне тәртипкә салу максатларында, «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру һәм «Бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 17 сентябрендәге 1013 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 151 номерлы карарына (24.01.2022 елның 42 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре бюджет өлкәсендәге аерым оешманың структур бүлекчәсе җитәкчесе сәркәтибенең вазыйфаи оклады күләменә бермә-бер исәпләнә, ул 12 688 сум тәшкил итә.»;

3 нче пунктның 3 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 15 проценты күләмендә;»;

7 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 15 проценты күләмендә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов